ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

30 01 2026 г. № 46

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль законы, «2026 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2026 елның 23 гыйнварындагы 30 номерлы карары Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Кама шәһәре, Кама Аланы шәһәр тибы поселогы һәм Түбән Кама муниципаль районы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында кабул ителгән килешүләрне исәпкә алып, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. 2026 елның 1 февраленнән Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен әлеге карарның 1нче һәм 2 нче кушымталары нигезендә 9 678,63 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2025 елның 31 гыйнварындагы 80 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы уставында билгеләнгән тәртиптә рәсми рәвештә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Җитәкче Р.М. Латыйпов

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 1нче кушымта
«30» ___01___ 2026 № ___

2026 нчы елның 1 нче февраленә Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Каберне һәм мәет күмү өчен кирәкле башка әйберләрне бирү һәм китерү | 802,56 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка ташу | 718,08 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 8 157,99 |
| Барлыгы | 9 678,63 |

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карарына 2 нче кушымта
«30» 01 2026 № 118

2026 нчы елның 1 нче февраленә Түбән Кама муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән бәясе исемлеге

| Хезмәтләр исемлеге | Хезмәт бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2. Кәфенлек (мәрхүмнең киеме) | 401,28 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 802,56 |
| 4. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратка күчерү | 718,08 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 7 756,71 |
| Барлыгы | 9 678,63 |